КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 май г.Казань № 650

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законны,

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләренең исемен кушымта нигезендә «спорт мәктәбе» дигән махсус исем белән өстәмә белем бирү дәүләт учреждениеләренә (алга таба - дәүләт учреждениеләре) үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга спорт төрләре буенча спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 20 сентябрь, 1020 нче карарына, аны әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә, үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне раслауга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына, Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләренә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы муниципаль учреждениеләрнең исемнәрен «спорт

мәктәбе» махсус исеме белән өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләренә үзгәртү буенча эш алып барырга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Дәүләт өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен алмаштыру турында» 2018 ел, 05 сентябрь, 759 нчы;

«Дәүләт өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен алмаштыру турында» 2019 ел, 21 гыйнвар, 28 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт өстәмә белем бирү учреждениеләре исемен алмаштыру турында» 2019 ел, 21 гыйнвар, 28 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 30 июль, 632 нче.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 май, 650 нче карарына кушымта

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре исемлеге

| Т/с | Дәүләт учреждениесе исеме үзгәртелгәнгә кадәр | Дәүләт учреждениесе исеме үзгәртелгәннән соң |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | «Фехтование буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе | «Фехтование буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү бирү дәүләт автоном учреждениесе |
| 2. | «Батыр» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе | «Батыр» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе |
| 3. | «Динамо» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе | «Динамо» республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе |
| 4. | «Тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | «Тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 5. | «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе | «Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге Шахмат, шашка, го буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе |
| 6. | «Атлы спорт буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | «Атлы спорт буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 7. | «Стендка ату һәм пуля белән ату буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | «Стендка ату һәм пуля белән ату буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 8. | «Көрәш буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе | «Көрәш буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесе |
| 9. | «Республика спорт-адаптив мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | «Республика спорт-адаптив мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 10. | «Акватика» спортның су төрләре буенча республика олимпия | «Акватика» спортның су төрләре буенча республика олимпия резервы спорт |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 11. | «Барс» кышкы спорт төрләре буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе | «Барс» кышкы спорт төрләре буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 12. | «Ф.Г.Вәлиевнын бадминтон буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учрежде-ниесе | «Ф.Г.Вәлиевның бадминтон буенча республика олимпия резервы спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |
| 13. | «Регби буенча республика спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учрежде-ниесе | «Регби буенча республика спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе |